# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^{1}$ статьясына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^{1}$ статьясындагы 6 пунктына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 8 март, 19 май), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"6. Муниципаль район составына керүче шәһәр яисә авыл җирлеге территориясендә даими яшәп, әлеге Кодексның 32 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлекләре алуда кызыксынучы гражданнарга җир кишәрлекләре тиешле шәһәр яисә авыл җирлеге чикләрендә йә, аерым муниципаль районның вәкиллекле органы норматив хокукый акты белән билгеләнгән очракларда, шушы муниципаль район составындагы башка җирлек чикләрендә бирелә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 29 мае
№ 27-ТРЗ